КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 сентябрь г.Казань № 793

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 ел, 16 август, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 ел, 16 август, 563 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 968 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«План буенча тикшерү үткәргәндә Идарәнең вазыйфаи затлары Идарә тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнелә һәм раслана торган тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) кулланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) куллану барлык юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне план буенча тикшергәндә гамәлгә ашырыла.

План буенча тикшерү үткәргәндә кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм индивидуаль эшмәкәргә карата куела торган мәҗбүри таләпләргә кагылышлы, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, мәдәни мирас объектларына (тарихый һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә зыян салу куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килүгә юл куймау күзлегеннән аларны үтәү аеруча әһәмиятле булган сораулар була.»;

19 нчы пунктның икенче – бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гадәттән тыш югары рисктагы категория өчен – елга бер тапкыр;

югары рисктагы категория өчен – ике елга бер тапкыр;

урта рисктагы категория өчен – дүрт елга бер тапкырдан ешрак һәм биш елга бер тапкырдан кимрәк түгел;

уртача рисктагы категория өчен – алты елга бер тапкырдан ешрак һәм сигез елга бер тапкырдан кимрәк түгел.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин